КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 октябрь г.Казань № 1313

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 13 август, 713 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче; 2022 ел, 11 март, 214 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 3 март, 200 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.8 пунктта «алты календарь айга» сүзләрен «айга» сүзенә алмаштырырга;

9.8 пунктта «алты календарь айга» сүзләрен «айга» сүзенә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 3 пунктындагы беренче абзацында «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары» сүзлә-

рен «федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче; 2021 ел, 12 июль, 567 нче; 2021 ел, 28 сентябрь, 918 нче; 2022 ел, 3 март, 194 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 11 июль, 809 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$2.3^1$ пунктта «алты календарь айга» сүзләрен «айга» сүзенә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 3 пунктындагы беренче абзацында «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе субъектлары» сүзләрен «федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 26 декабрь, 120 нче; 2020 ел, 17 апрель, 304 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2021 ел, 10 апрель, 236 нчы; 2022 ел, 28 гыйнвар, 66 нчы; 2022 ел, 24 май, 484 нче; 2022 ел, 14 декабрь, 1325 нче; 2023 ел, 4 февраль, 100 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә булса да инвалид бала булган гаилә әгъзаларына ай саен пособие бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

$4^2$ пунктта «алты календарь айга» сүзләрен «айга» сүзенә алмаштырырга;

16 пунктта «дәүләт хакимияте органнарына» сүзләрен «дәүләт органнарына» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында» 2019 ел, 3 декабрь, 1095 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 декабрь, 1234 нче; 2023 ел, 4 февраль, 100 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлеше белән күздә тотылган дару чаралары һәм башка даруханә

ассортименты товарлары сатып алуга түләү бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«бала (балалар) тулысынча дәүләт тәэминатында булу;

гариза бирүчене гариза бирелә торган балага (балаларга) карата ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү);

бала опекада (попечительлектә) булуы һәм опекун (попечитель) аны тәрбияләп караган өчен акча алу;

гариза бирелгән балага карата ата-ананың алимент йөкләмәләре барлыкка килү;

гариза бирү тарафыннан тулы булмаган һәм (яки) белә торып дөрес булмаган белешмә бирү.».

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 март, 129 нчы; 2021 ел, 24 май, 365 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1076 нчы; 2022 ел, 5 декабрь, 1286 нчы; 2022 ел, 30 декабрь, 1479 нчы; 2023 ел, 31 июль, 913 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Балалар кирәк-яракларының бүләк комплектын алу хокукын билгеләү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме күләмен исәпләү һәм гаиләнең җан башына уртача кереме күләме хакындагы белешмә кәгазен бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктның икенче абзацында «алты календарь айга» сүзләрен «айга» сүзенә алмаштырырга;

1.6 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин